# Саба җаен таба

ГӨЛГЕНӘ ШИҺАПОВА

**Татарстан күләмендә зур үрләр яулаган урман хуҗалыклары җитәкчеләрен Саба районы Лесхоз авылы үзенә җыйды.**



А. НАСЫРОВ

**Әлеге үзәк бу өлкәдәге яңа алымнарны үзләштерү өчен зур мөмкинлекләр бирә**

Бирeдә Россиядә тиңе булмаган Урман селекция-орлыкчылык үзәге ачылды. Тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, урман хуҗалыгының федераль агентлыгы җитәкчесе Виктор Масляков, Федерация Советы әгъзасы Ралиф Сафин, ТР Урман хуҗалыгы министры Наил Мәһдиев, "BBC AB" компаниясенең (Швеция) сатулар буенча җитәкчесе Андреас Бернер катнашты. "Бүген Татарстан һәм Россиядә яңа үсентеләр белән урман мәйданнарын саклап калу мөмкинлегe туды. Әлеге үзәк бу өлкәдәге яңа алымнарны үзләштерү өчен зур мөмкинлекләр бирә. Бу – сез киләчәк буыннар хакына яшисез дигән сүз",– диде Виктор Масляков. Кунак тантанага буш кул белән килмәгән. Ул Саба урманчылыгы җитәкчесе Вәсил Гыйззәтуллинга телевизор бүләк итте.

– Модернизацияләү урман хуҗалыгына да килеп җитте. Урманнарның нигезе булып питомниклар санала. Әлеге хезмәт гаять катлаулы. Үзәк безгә бик тә кирәк иде. Бу Татарстан урманнарын үстерүдә җитди этәргеч булачак. Безнең бурыч исә әлеге мөмкинлекне нәтиҗәле файдалану. Яңа технологияләргә нигезләнеп, заманча җиһазландырылган бу үзәктә сыйфатлы үсентеләр алу мөмкин булачак. Үзәк республика өчен генә түгел, бирeдә Россиянең төрле төбәкләреннән килеп тәҗрибә уртаклашырга, фикерләшергә мөмкин булачак. Без Татарстанда дөнья дәрәҗәсендәге яңа алымнарны күрәбез", – ди Рөстәм Миңнеханов. Республика җитәкчесе җирле урман хуҗалыгы җитәкчелегенә интерактив такта бүләк итте. Ралиф Сафин исә үз чыгышында, ник Татарстанда туып үсмәгәнмен икән, дип әйтеп узды. "Татарстан белән, чыннан да, горурланырлык. Алда эшлисе эшләр әле байтак", – дип, үзәккә автобус һәм йөк машинасы тапшырды. Швециядән килгән кунак Андреас Бернер: "Бу үзәкнең тиңе юк. Әлеге питомник күләме һәм автоматлаштыру дәрәҗәсе буенча уникаль. Бу әле эшнең башы гына дип уйлыйбыз, чөнки Россиядә үсентеләргә ихтыяҗ зур. Питомникта елына 12 миллион үсенте үстерелер дип көтелә", – диде.

Әлеге үзәкнең лабораториясендә бер агачтан 100 мең үсенте алырга исәплиләр. Чери торган усак, каен агачларының геннарын үзгәртеп, аларны төрләндерергә хыялланалар. Хәзерге вакытта урманнар территориясе 17 процент кына тәшкил итә. Мондый мөмкинлекләр булганда бу мәйданны 25 процентка җиткермәкчеләр.